**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2020 ел, 3 август №302

**Татарстан Республикасы Апас районы төзелүгә 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль турында нигезләмә**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы төзелүгә 90 ел тулу уңаеннан Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы **карар итте**:

1.Татарстан Республикасы Апас районы төзелүгә 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медальне гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Апас районы төзелүгә 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль турында нигезләмәне расларга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**Апас муниципаль районы**
**Башлыгы**
**Апас муниципаль районы**
**Советы рәисе** **Р.Ф. Хисамутдинов**

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы Советының
2020 елның 3 августагы
302 номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Апас районы төзелүгә 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль турында нигезләмә**

1.Татарстан Республикасының дәүләт, социаль-икътисадый, фәнни һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән гражданнар Татарстан Республикасы Апас районы оешуга 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль белән бүләкләнә.

2.Татарстан Республикасы Апас районы төзелүгә 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль юбилей датасына багышланган.

3.Истәлекле медаль диаметры 31 мм. Билгенең алгы ягында, үзәктә - диаметры -22 мм булган Апас муниципаль районы гербы сурәте . Билгенең суң ягында – «АПАСТОВСКИЙ РАЙОН», уңда – «АПАС РАЙОНЫ» язулары, аста - «1930», «90», «2020» саннары.

Барлык сурәтләр һәм язулар рельефлы.

Истәлекле медаль Апас муниципаль районы флагы төсләрендәге тасма белән бизәлгән.

4.Татарстан Республикасы Апас районы төзелүгә 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль белән бүләкләү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгы каршындагы бүләкләү комиссиясе тарафыннан башкарыла.

Комиссия эшенә киңәш бирү хокукы белән иҗтимагый оешмалар, туган якны өйрәнү музее вәкилләре җәлеп ителә.

5.Татарстан Республикасы Апас районы төзелүгә 90 ел тулу уңаеннан истәлекле медаль белән бүләкләү турындагы карар Апас муниципаль районы Башлыгы тарафыннан кабул ителә һәм боерык белән рәсмиләштерелә.

6.Истәлекле медаль тапшыру тантаналы шартларда, шул исәптән Апас районы оешуга 90 ел тулуга багышланган муниципаль бәйрәм чаралары кысаларында башкарыла.

7.Истәлекле медальнең тиражы-1000 данә.